■ Хәзрәт вәгазе

# ҮЗЕҢНӘН БАШЛА

Шамил ГАЛӘВЕТДИН,
Россиянең Европа өлеше мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе урынбасары, Мәскәүдәге Мемориаль мәчете имамы

“Дөреслектә, Аллаһы Тәгалә һәр эштә гадел булырга һәм дин вә мөселманнар файдасына яхшы эшләр кылырга, вә якын кадәшләрнең хакын үтәргә боерадыр, вә Аллаһ сезне тыядыр фәхеш-харам эшләрдән, вә шәригать белән сабит булмаган бидгать гамәлләрдән һәм зураеп хактан качудан, хаксыз золым итүдән...”.

Аллаһыны истә тотыгыз һәм Ул сезне онытмас...

Аннан гафу сорагыз һәм Ул сезне гафу итәр!

“...Сезгә үзегезне тикшерү, тәзәтү ляземдыр, әгәр туры юлга күңелсәгез, адашкан кеше сезгә зарар итә алмас...”.

Ачык һәм яшерен булган нәрсәләрне Белүче Аллаһының исеме белән башлыйм.

“Кешеләр арасында монафыйклар да бар, алар Аллаһуга һәм Ахирәт көненә ышандык диләр, ләкин үзләре ышанучы түгелләр. Ул монафыйклар Аллаһуны һәм мөселманнарны алдамакчы булалар, ләкин һич алдый алмаслар, фәкать үзләрен алдыйлар, шуны сизмиләр”.

Сорау: “Әгәр без кардәшебездә тышкы яктан монафыйклык сыйфатлары барлыгын сизсәк, аны “монафыйк” дип атарга хакыбыз бармы?”.

Җавап: “Юк!”

Моңа берничә дәлил китерәм.

1. Сугыш вакытында сәхабәләр арасыннан берәүнең, дошманының “Аллаһыдан башка илаһ юк һәм Мөхәммәд Аның Илчесе” дип үлеме алдыннан шәһадәт китерүенә дә карамастан, бу сүзләрне ихластан әйтмәде дип уйлап, аны һәлак итүен ишеткәч, Пәйгамбәр (салаллаһу галәйһи вәссәләм): “Син аның йөрәген ачып, эчендә ни барлыгын күрдең мәллә?!” - дип ачыргаланып кычкырып җибәргән.

2. “Гасыр белән ант итәм! Дөреслектә, кеше хәсрәттә. Мәгәр иман китереп, Ислам динен кабул иткән, һәрвакыт изге гамәлләр кылган, һәм бер-берсен хаклыкка, дөреслеккә, гаделлеккә өндәгән һәм тормыш вә дин мәшәкатьләренә, килгән төрле авырлыкларга, бәла-казаларга сабыр итәргә, чыдамлы булырга берберсен өндәгән кешеләр генә хәсрәттә булмаслар”.

Мөселман изге гамәлләр генә кылучы булырга тиеш. Кардәшен монафыйклык гөнаһыннан коткару өчен ул хәленнән килгәннең барысын да эшләргә бурычлы. Әлеге түбән кешелек сыйфатына ия булган мәхлукка, вакытында йогынты ясамыйча, узындырып җибәрү, аны упкынга төртеп төшерүгә тиң. Әгәр кечкенә генә ярамаган эш өчен дә кардәшебезне тиеге яки бу гөнаһлылар рәтенә кертеп, аны монафыйклыкта, имансызлыкта һәм әхлаксызлыкта гаепләсәк, иртәгә үзебез үк Иблис мәлгуньнең кармагына эләгүебез ихтимал. Ул безне җиңел генә алдаларга да күп сорамас: Җәһәннәмнең төбенә тәгәрәрлек дәрәҗәдә гөнаһ кылуыбызны сизми дә калырбыз...

Бөек Аллаһыбыз безне ләгънәт кылынган Иблиснең мәкереннән һәм капканыннан сакласын!

“Ничек шулай инде, - дип сорарсыз. - Пәйгамбәребез (салаллаһу галәйһи вәссәләм): “Монафыйк ул шундый сыйфатларга ия: вәгъдә бирсә, вәгъдәсендә тормый; ялганлый; үзенә ышанган кешене кыен хәлдә калдыра”, - дигән хәдис бар, аңа таянып, әлеге сыйфатларга ия булган кешеләрне монафыйк дип атарга мөмкин!”.

Бу шулай - тик! - беренче чиратта үзебезне тикшереп карыйк: әлеге сыйфатлар безгә дә хас түгелме, Ә алдагы критерийларны башкаларга карата кулланып, ашыгычлы нәтиҗәләр чыгару, - бик куркыныч хәл. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (салаллаһу галәйһи вәссәләм) әйткән: “Берәү дин кардәшен имансызлыкта гаепләсә, әлеге гаеп икесенең берсенә әйләнеп кайтачак: әйтелгән сүз дөрес булган очракта, гаепләү кемгә юнәлгән булса, шуңа атылачак, дөрес булмаган очракта, гаепләүченең үзенә кайтачак”, “Мөселманны тиргәү һәм хурлау - ул туры юлдан тайпылу...”.

Әлеге тезисларны тикшереп карыйк.

1. “Әгәр мөселман вәгъдә биреп, аны үтәмәсә”, димәк, ул монафыйклык сыйфатына ия. Әмма сез аятьтә язылган: “Аллаһ һичкемгә көче җитмәгәнне йөкләмәс...”, дигән сүзләрне онытмагыз. Кеше гаять җитди сәбәпләр аркасында да вәгъдәсендә тора алмаска мөмкин.

2. “Әгәр кеше алдалый икән”, димәк, ул монафыйк. Ихтимал. Әмма Изге Коръән һәм Сөннәт юлыннан баручыларга ялгышып, онытылып кылынган хаталары кичерелә. Бәлкем, ул бу хакта онытканды яисә хаталангандыр. Пәйгамбәребез (салаллаһу галәйһи вәссәләм) әйтте: “Минем өммәтем хаталанып, онытылып һәм ирексездән кылган гамәлләре өчен җавапка тартылмас”.

3. “Үзенә ышанган кешене кыен хәлдә калдыра”. Ләкин безнең барыбыз да катлаулы хәлләрдә тыелган гамәлләрне кылырга яраганлыгын беләбез. Һәм, хәлнең ни дәрәҗәдә кискен торуыннан чыгып, аны йомшартучы шартлар да туарга мөмкин. Шуңа күрә, мөселманның сезне шундый җитди шартларда кыен хәлдә калдырган булуы да ихтимал. Безгә шуны да истән чыгарырга ярамый: дин кардәшләребезгә карата фикерләребез кара төсмерләргә буяла барган саен, Бөек Аллаһыбызның ачу болытлары безнең - нәкъ менә безнең(!) - өстебездә куерачак. Пәйгамбәребезнең (салаллаһу галәйһи вәссәләм): “Мөселманның мөселманга каны, милке, намусы харам һәм кагылгысыз”, - дип әйткән сүзләреннән һәрберебез хә-бәрдар.

Моңа дәлил булып “Хуҗурат” сүрәсенең 12нче аятендә: “Ий, мөэминнәр, күп гөманнан (уйлардан) сакланыгыз, тәхкыйк, бәъзе гөманда гөнаһ бар. Вә кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, кеше гаебен әзләмәгез вә бәгъзегез бәгъзегезгә гайбәт кылмасын!” - дип әйтелә.

Бөек Аллаһыбыз безгә фикер-уйларыбыздан башлап һәр гамәлебездә дә хакыйкый мөселман һәм мөэмин булып калырга ярдәмен бирсен!

“Дөреслектә Аллаһы Тәгалә һәр эштә гадел булырга һәм дин вә мөселманнар файдасына яхшы эшләр кылырга, вә якын кардәшләрнең хакын үтәргә боерадыр, вә Аллаһ сезне тыядыр фәхеш-харам эшләрдән, вә шәригать белән сабит булмаган бидгать гамәл-ләрдән һәм зураеп хактан качудан, хаксыз золым итүдән...”.

Аллаһыны истә тотыгыз һәм Ул сезне онытмас...

Аннан гафу сорагыз һәм Ул сезне гафу итәр!



## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рәжәб 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Рәжәб | Аҙна көндәре | июнь, июль | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сығы | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Йома | 3 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.11 | 22.41 | 00.01 |
| 2 | Шәмбе | 4 | 4.17 | 5.47 | 14.30 | 21.12 | 22.42 | 00.12 |
| 3 | Йәкшәмбе | 5 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.13 | 22.43 | 00.13 |
| 4 | Дүшәмбе | 6 | 4.15 | 5.45 | 14.30 | 21.14 | 22.44 | 00.14 |
| 5 | Шишәмбе | 7 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.15 | 22.45 | 00.15 |
| 6 | Шаршамбы | 8 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.16 | 22.46 | 00.16 |
| 7 | Кесе йома | 9 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.17 | 22.47 | 00.17 |
| 8 | Йома | 10 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.18 | 22.48 | 00.18 |
| 9 | Шәмбе | 11 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.19 | 22.49 | 00.19 |
| 10 | Йәкшәмбе | 12 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.20 | 22.50 | 00.20 |
| 11 | Дүшәмбе | 13 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 12 | Шишәмбе | 14 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.21 | 22.51 | 00.21 |
| 13 | Шаршамбы | 15 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.21 |
| 14 | Кесе йома | 16 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.22 | 22.52 | 00.22 |
| 15 | Йома | 17 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 16 | Шәмбе | 18 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |
| 17 | Йәкшәмбе | 19 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 18 | Дүшәмбе | 20 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 19 | Шишәмбе | 21 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 20 | Шаршамбы | 22 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 21 | Кесе йома | 23 | 4.11 | 5.41 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 22 | Йома | 24 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 23 | Шәмбе | 25 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.25 | 22.55 | 00.25 |
| 24 | Йәкшәмбе | 26 | 4.12 | 5.42 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 25 | Дүшәмбе | 27 | 4.13 | 5.43 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 26 | Шишәмбе | 28 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 27 | Шаршамбы | 29 | 4.14 | 5.44 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 28 | Кесе йома | 30 | 4.15 | 5.45 | 14.30 | 21.24 | 22.54 | 00.24 |
| 29 | Йома | 1 | 4.16 | 5.46 | 14.30 | 21.23 | 22.53 | 00.23 |

## ЙОМГАК

Газа секторында Израиль операциясе вакытында интернетта шундый мөрәҗәгатькә юлыктым:

“Мин палестиналыларга ярдәм итәргә әзер, кем минем белән?” Укуымны дәвам итеп, бу чакыру өчен кәтелмәгән тәкъдимнәргә тап булдым. Автор Аллаһы белән бәйләнешне түбәндәге нәсыйхәт белән ныгытырга чакыра:

- һәр иртәнге һәм төнге намазны җәмәгать белән мәчеттә укырга;

- һәр намаздан соң Коръәннең берәр битен укырга;

- Кунут догасын (бәла-каза вакытында укыла) ятларга һәм аны намаз саен укырга;

- һәр төндә тороп тәһәҗҗуд намазын укырга;

- Аллаһыны һәрвакыт зикер итәргә.

Мондый кеше Газа секторына китә алмаган. Ул башкасын эшләгән - проблеманың тамырын күрә алган. Ул үзүзенә шундый сорау биргән: ни өчен соң Ислам җәмәгате палестиналыларга бернинди ярдәм күрсәтә алмаслык дәрәҗәдә, шулкадәр йомшак, Бу сорауга миллион төрле җавап табып булыр иде: Куркак галимнәр, сатлык хакимнәр...

Һәм хәтта бу дөрес булса да, ул моны үзгәртә алыр идеме? Юк. Ул үзенең гаебен тапкан: Аллаһыдан куркуы сәхабәләрнең Аллаһыдан куркуыннан бик ерак торуын аңлаган. Үз йомшаклыгының өммәт йомшаклыгына бер өлеш булып торуын күргән. Әгәр ул көчен арттырса, өммәтнең көче дә бер кешегә артачак. Иншә Аллаһ!

Һәр намазда без, кагыйдә буларак, ачылыш догасын (вәҗҗагту) укыйбыз, анда шундый сүзләр бар: “...минем намазым, корбаным, яшәвем һәм үлемем Галәмнәр Хуҗасы Аллаһы хөкемендә...” Әгәр без намазыбызда шушы доганы укыйбыз икән, бу - бик яхшы. Мәгънәсен аңлап укысак, тагын да яхшырак.

Ә инде шушы сүзләрне чынга ашырса алсак, без иң катлаулы ниятләребезне дә, тәкъдим иткән кебек үк, җиңел генә тормышка да ашырырбыз. Аллаһы безне ярдәменнән ташламасын.